Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең
Иске Михайловка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

23 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2020елның 20 ноябрендә 14 сәгать00 минутта, 2020 елның 20 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта, 2020елның 20 ноябрендә 18 сәгать00 минутта, узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә: "Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авылы җирлеге Иске Михайловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: спорт мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү, кышкы һәмҗәйге айларда карап тоту, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерүөчен түләү?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 203 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 127 кеше, бу 63 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 74«РИЗА»позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 53«КАРШЫ»позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловкаторак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Иске Михайловка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2021елда 500 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрнебашкаруга юнәлдерергә: спорт мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү, кышкы һәм җәйге айларда карап тоту, сметалар төзү, техник күзәтүүткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

4.Әлеге карарны«Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Иске Михайловка авылы, Школьная урамы, 43 нче йорт, Иректе авылы, Лесная урамы, 1а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматларрәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты«Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче И.М.Абдуллин